ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасының бәйрәм һәм истәлекле көннәре турында” Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2016 елның 21 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасының бәйрәм һәм истәлекле көннәре турында” 1992 елның 19 февралендәге 1448-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы 5 өлешенә (2010 елның 14 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 4; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 10 (II өлеш), “ял көне бәйрәм көненнән соң килүче эш көненә күчерелә” сүзләрен “ял көннәренә өстәмә ял көне бирелми” сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2016 елның 29 сентябре
№ 67-ТРЗ